**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү**

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез (алга таба - проект).

Проектның мәгълүмати материаллары:

- территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә;
- җирлекнең җирле әһәмияттәге объектларын планлаштырып урнаштыру картасы;
- торак пунктларның чикләре картасы (шул исәптән төзелә торган торак пунктларның чикләре);
- функциональ зоналар картасы;
- җирлек составына керүче торак пунктлар чикләре турында белешмәләр, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен кулланыла торган координаталар системасында әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге;
- Генераль планны нигезләү материаллары.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:

Проект буенча гавами тыңлаулар 2026 елның 10 февраленнән 2026 елның 20 февраленә кадәр үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

- гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр итү;
- проектны һәм мәгълүмат материалларын аның янына рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлауларның беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Богородский авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бөтен территориясендә (алга таба - Богородский авыл җирлеге) торак пунктлар өлешендә - Богородский авылы, Гильдеево авылы, Көек авылы, Беренче Май поселогы, Ильинский поселогы, Черниково авылы, Камыш авылы) уздырыла.

Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:

Проектлана торган объект, территорияне планлаштыру документлары буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре;

- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга хокук ияләре.

Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру датасын, вакытын һәм урынын билгеләргә:

- Камыш авылында яшәүчеләр өчен: 2026 елның 18 февралендә 13 сәгать 00 минутта (ФАП янындагы территория) түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Камыш авылы, Ягодная ур., 1А йорты;

- Беренче Май поселогында яшәүчеләр өчен: 2026 елның 18 февралендә 13 сәгать 30 минутта (кибет янындагы территория) түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Беренче Май поселогы, Центральная ур., 18Б йорты;

- Гильдеево авылында яшәүчеләр өчен: 2026 елның 18 февралендә 14 сәгать 00 дә, (кибет янындагы территория) түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Гильдеево авылы, Верхняя ур., 44А йорты;

- Көек авылы халкы өчен: 2026 елның 18 февралендә 15 сәгать 00 минутта (балалар бакчасы янындагы территория) түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Көек авылы, 26 нчы Квартал ур., 3 нче йорт;

- Богородский авылы халкы өчен: 2026 елның 18 февралендә 16 сәгатьтә (Богородский авыл клубының тамаша залы) түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Богородский авылы, Центральная ур., 57Б/1 йорты;

- Ильинский поселогында яшәүчеләр өчен: 2026 елның 18 февралендә 17 сәгать 30 минутта (кибет янындагы территория) түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Ильинский поселогы, Лесная урамы, 33 йорт;

- Черниково авылы халкы өчен: 2026 елның 18 февралендә 18 сәгать 00 минутта (торак йорт янындагы территория) түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Черниково авылы, Зеленая ур., 27 й.

Проект экспозициясен оештырырга:

- 2026 елның 17 февралендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб - адрес буенча: https://pestreci.tatarstan.ru/territorialnoe-planirovanie-487142.htm «Проектлар экспозициясе» вкладкасында, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында түбәдәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авылы, Үзәк ур., 30А й.

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында веб буенча

урнаштырылган проект материаллары белән - https://pestreci.tatarstan.ru/territorialnoe-planirovanie-487142.htm экспозициянең бөтен срогы дәвамында тәүлек буе танышырга мөмкин. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында әлеге проект белән 2026 елның 17 февралендә 09.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр (12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр ял вакыты) танышырга була.

2026 елның 17 февраленнән 2026 елның 18 февраленә кадәр гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- язмача яисә электрон документ рәвешендә гавами тыңлаулар оештыручы адресына, адресы буенча: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авыл җирлеге, Богородский авылы, Центральная ур., 30А йорт, e-mail: bog.pes@tatar.ru;

- Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Богородский авылы, Центральная ур., 30А й. адресы буенча проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу кенәгәсендә (журналында) исәпкә алу юлы белән;

- гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү барышында язма яисә телдән формада.

Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кыска формада, мондый тәкъдимнең яисә кисәтүнең төгәл формулировкасы белән бәян ителергә тиеш.

Гавами тыңлауларда катнашучылар идентификация максатларында үзләре турында белешмәләр (фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туу датасы, яшәү (теркәү) урыны адресы - физик затлар өчен; исеме, төп дәүләт теркәве номеры, урнашу урыны һәм адресы - юридик затлар өчен) тапшыралар, мондый белешмәләрне раслый торган документлар кушып.

Тиешле җир кишәрлекләренә һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына һәм (яисә) күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарга хокуклы булган гавами тыңлауларда катнашучылар шулай ук мондый җир кишәрлекләре, капиталь төзелеш объектлары, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналар, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан булган урыннар турында белешмәләр һәм мондый җир кишәрлекләренә, капиталь төзелеш объектларына, күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга хокукларын билгели яисә раслый торган башка документлар тапшыра.

Гавами тыңлауларда катнашучылар тәкъдимнәр яисә искәрмәләр керткәндә «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә гавами тыңлаулар оештыруга ризалыгын бирәләр.

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru), «Вперед» («Алга») район газетасында һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге мәгълүмат стендларында әлеге хәбәрне бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Д.Ю. Булыгин